Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Суркино авыл Советы

КАРАРЫ

16 июль 2024 ел № 100

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 177 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Иске Суркино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 177 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 238 номерлы, 2015 елның 05 маендагы 260 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 129 номерлы, 2020 елның 18 ноябрендәге 9 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 90 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә (территорияләргә) карата казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр («урам-юл челтәре», «территорияне төзекләндерү» куллану төрләрен кертеп»).»;

1.2. 5 пунктның алтынчы абзацын җиденче абзац дип санарга.

2. Әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, Әлмәт районы,Иске Суркино авылы, Үзәк урамы, 77 йорт, Яңа Суркино авылы, Үзәк урамы, 12а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Иске Суркино авыл
җирлеге башлыгы Н.В. Леонтьев